“Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Шәмбалыкчы авыл җирлегенең Ябалак авылында халык җыены нәтиҗәләре һәм 2024 елда үзара салым кертү турында» 2023 елның 29 ноябрендәге 5 номерлы карарын үзгәртү буенча халык җыены нәтиҗәләре турында”

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Шәмбалыкчы авыл җирлегенең Ябалак авылында
2024 елның 20 мартындагы 3 номерлы халык җыены карары

“Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Шәмбалыкчы авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда халык җыенын әзерләү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 10 сентябрендәге 137 номерлы Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Шәмбалыкчы авыл җирлеге Советы карарыны туры китереп

2024 елның 20 мартында үткән “Сез Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Шәмбалыкчы авыл җирлегенең Ябалак авылындагы халык җыенының нәтиҗәләре һәм 2024 елда үзара салым кертү турында» карарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча эшләр исемлеге өлешендә үзгәртү һәм 2024 елда алынган үзара салым акчаларын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге чараларны гамәлгә ашыруга юнәлдерү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;
- торак пункт территориясен төзекләндерү.

дигән мәсьәлә буенча Ябалак авылы халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзеде.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә буенча:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 183 кеше кертелгән, тавыш бирүдә кеше катнашкан гражданнар саны 111 кеше .

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда 111 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Шәмбалывкчы авыл җирлегенең Ябалак авылында халык җыенын узган дип, халык җыенының нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2.Халык җыенында карарлган мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. 2024 елда алынган үзара салым акчаларын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге чараларны гамәлгә ашыруга юнәлдерергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;
- торак пункт территориясен төзекләндерү.

4.Әлеге карарны мәгълүмат стендындлары аша халыкка белдерергә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Шәмбалыкчы авыл җирлеге
Башлыгы Ф.Ф.Миннуллин